**Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры Т.Җ. Сөләймановның «Яшьләргә милли тәрбия бирүдә дәвамчылыкны тәэмин итү»темасына доклады**

Хәерле көн, хөрмәтле Марат Готыф улы, хезмәттәшләр һәм чакырылган кунаклар!Бүгенге көндә яшьләр сәясәте ул, әлбәттә, яшьләр эшләре министрлыгы эше белән генә чикләнми. Яшьләр сәясәтеул–яшьләр үзләренең потенциалын һәм проектларын тормышка ашыра алырлык мөмкинлекләр булдырылган мохит. Шуңа дабезнең бурыч –яшьләр тормышы, интеллектуаль, рухиүсеше, ялы һәм аралашуы өчен мохит тудыручылар белән тыгыз элемтәдә булып эш итү.

Әлбәттә, милли сәясәт ул -үткәрелә торган чаралар гына түгел, ул - мохит тә,кешене әйләндереп алганмохит, аның яшәү рәвешен,үсешен һәм тормыш кыйммәтләрен билгели торган мохит.Бу аның кигән киемендә дә, тыңлаган көйләрдә, аралашкан, ишетелгән сүзләрдәдә чагылыш таба.Кайсы бер сүзләрнең мәгънәләре бер ишетүдә аңлашылып җитмәсә дә, заманча яңгыраштa булганда,яшьләр арасында популярлаша. Мәсәлән, яшьләр арасында популяр булып өлгергән экстрим-парк УРАМ дип атала. Болар барысы да, әлбәттә, милли сәясәт элементлары.

Яшьләр милли кыйммәтләрне кабул итсен, сеңдрсен, үз итсен өчен иң тиз һәм үтемле ысулларының берсе – яшьләр берләшмәләре аша аларга кирәкле мәгълүматны җиткерү.

Шуңа күрә, милли кыйммәтләрне, миллилекне кирәкле аудиториягә җиткерүдә безнең иң төп партнерларыбыз – яшьләр берләшмәләре һәм оешмалары. Уртак максатларның берсе булып, яшьләрдә милли үзаң тәрбияләү тора. Бу эштә безгә «Сәләт» хәрәкәте, «Идел», Татар яшьләре форумы, Татарстан халыклары яшьләр ассамблеясеһәм башка яшьләр оешмалары ярдәм итә.

Милли тәрбия буыннан-буынга күчеп барсын өчен яшьләр өчен уздырылучы чараларның системалы рәвештә ел саен яңартылып дәвам итүе мөһим.**«Сәләт» берләшмәсенең**сәләтле балаларны барлау һәм аларга ярдәм итү системасыбүгенге иң үтемлеүрнәкләрдән дип әйтеп була. «Сәләт» проектларының дәвамлы булуы турыдан-туры аның катнашучыларына бәйле. Аланнар сменаларында һәм

проектларында Сәләттә үскән кадрлар әйдаманнар, директорлар, укытучылар булып эшли, шулай ук, Сәләттәкатнашкан активистларның балалары да хәрәкәткә кушыла. Мәсәлән,«Бәләкәч» клубы чараларына кайчандыр сәлкеш, әйдаман булган бүгенге әти-әниләр мәктәпкәчә яшьтәге балалары белән киләләр.

2020 елдан башлап Казан шәһәренең 51нче номерлы гомуми белем бирү мәктәбе базасында «Асылташ» Сәләт мәктәбенең 2 сыйныфы, 1-нче Ә һәм 2-нче Әэшләп килә. Укучылар 3 телле мохиттә - татар теле, рус теле һәм инглиз теле мохитендәтәрбияләнә, белем ала. Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич кушуы белән 2021 елда Республикадагы 4 “Адымнар” полилингваль мәктәбендә “Сәләт” класслары ачылды. Ул классларның ачылуының төп мәгънәсе дә “Адымнар”да татар мохитен тагын да ныгыту һәм үстерү юнәлешендә “Сәләт” оешмасы потенциалын, аның бүгенге мөмкинлекләрен дә куллану.Бүгенге көндә бу активлык мәктәп программасы кысаларында, “Сәләт” катнашында, Яшьләр министрлыгы һәм Мәгариф һәм фән министрлыгы контролендә матур гына дәвам итә.

Татарстан районнары һәм шәһәрләрендә, шулай ук Башкортстан, Чувашияреспубликаларындаһәм Самара өлкәсендә хәрәкәт итүче 20-дән артык “Сәләт” клубы, һәр җәйдә үткәрелүче 25-ләп профильле укыту-сәламәтләндерү сменалары, Биләрдәге уку-укыту форумнарында һәр елны 20 меңләп яшьләр һәм балалар катнаша.Сменаларда катнашу өчен татар телен камил белү мәҗбүри, булмаса да, бу аланнарда һәм форумнарда татар телле мохит тудырыла, тәрбия бирү, мәдәни чаралар программалары туган телебездә үткәрелә.

Сменага килгән бала тулысынча татар мохитенә эләгә: элмә такталардагы язулар, әйдаманнар белән аралашу, чаралар, радиодан яңгыраган җырлар - барысы да татар телендә. Уку-укыту чараларының да күп өлеше татар телендә уза.

Җәй дәвамындааланнарда 3-5әр мәртәбә катнашучы кызлар һәм малайлар да бар. Вакыт үтү белән, бала татар телендә сөйләшә, мәдәниятне аңлыйбашлый, күренекле шәхесләр белән таныша. Бу балаларның бер өлеше киләчәктә «Сәләт»кә әйдаман булып кайта.Ә әйдаман булу өчен төп таләп – татар телендә әйбәт сөйләшү.

Иң актив әйдаманнар смена җитәкчеләре дәрәҗәсенә күтәрелә ала. «Сәлкеш-әйдаман-башҗитәк»чылбыры ул – нинди дә булса кыйммәтләрне башкаларга

тапшыру гына түгел. Бу – бик мөһим кадрлар мәктәбе. Бу кадрлар – татар мәдәниятен үстерүчеләр, телне һәм тарихны белүчеләр.

«Сәләт» берләшмәсендә татар телен белүгә юнәлдерелгән 50-дән артыккүләмле проектлар тормышка ашырыла: интеллектуаль сәләтле балалар һәм яшьләр иҗаты фестивале, «Болгар – Туган Тел» чатырлы аланы, «Сәләт-Олимп»олимпиадага әзерләнү мәктәбе, Сәләт хәрәкәтендә актив балалар, яшьләр, остазларга бирелә торган «Сәмрух»Республикакүләм Ел премиясе һәм башкалар.

Шулай ук иҗат юнәлшенә бәйле проектлар да гамәлгә ашырыла. Мәсәлән,«БикаФест» яшьләр җыр-шигърият фестивале, «Сәләткә нур булган йолдызлар» ачык әдәби конкурсы, «Яшь йөрәкләр»театраль лабораториясе һ.б. Бу проектларның төп максаты – татар халкының гореф-гадәтләрен, аның мәдәниятен һәм тарихын буыннан-буынга тапшыру.

Республикабызда яшәүче халыкларның мәдәни мирасын яктыртуга юнәлдерелгән яшьләр проектларын гамәлгә ашырырга булышу – безнең бурыч. Бу эш грант конкурслары аша башкарыла – яшьләр үзләренең проектларына акчалата ярдәм ала.

Дизайнер киемнәре һәм сувенирларның кечкенә брендларыннан башлап, TatCultFest, Печән базары, Этностартапфорум кебек зур һәм әһәмиятле вакыйгаларга кадәр – барысы да яшьләр тарафыннан уйлап табылганһәм тормышка ашырыла. Бу юнәлештә потенциал зур дип саныйбыз, кечкенә авылларда яшәүче яшьләр дә төрле шәп фикерләр, идеяләр белән министрлыкка килептора.

Шуңа бәйле рәвештә, Министрлык эшчәнлеге кысаларында «Милли - заманча»проект офисы булдырылды, ел саен «Таба» яшьләр этно-проектларының форумы тормышка ашырыла.

Без аны төрле халыкларның күпгасырлык мәдәниятенең яңа форматларын һәм яңа яңгырашын эзләү, этно-юнәлештә яшьләр өчен чын-чынлап кирәкле булган актуаль проектларны үстерү, ярдәм итү һәм тарату максатыннан башлап җибәрдек. Иң яхшы проектларга грантлар каралган.

**Татарстан халыклары яшьләр ассамблеясе** 30 яшьләр милли-мәдәни хәрәкәте вәкилләрен, Африка һәм гарәп студентлары берләшмәләрен үз эченә ала. Республиканың 20 муниципаль районында үз вәкиллекләре бар.

Яшьләр ассамблеясы үз проектлары аша төрле милләт яшьләре арасында татар мәдәнияте, гореф-гадәтләре һәм тарихы белән кызыксыну формалаштыра.

Ел саен үткәрелә торган республика яшьләр милләтара чаралар арасында: традицион музыкасының заманча яңгырашын популярлаштыруга юнәлдерелгән «Этномузыка фестивале»,«Халыклар дуслыгы–Татарстан байлыгы» уку-укыту форумы. Шулай ук, «Безнең геройлар» әдәби марафонын да билгеләп үтәсем килә. Марафонның максаты – яшьләрне Муса Җәлил һәм Җәлилчеләр иҗаты белән таныштыру, конкурс аша аларның әдәби әсәрләренә карата кызыксыну уяту иде.

Төрле илләрдә сибелеп яшәүче татар яшьләренберләштерү һәм милли проектларны тормышка ашыру, белем бирү чараларын оештыру һәм уздыруда**Бөтендөнья Татар Конгресы нигезендәБөтендөнья татар яшьләре форумы** берләшмәсе эше зур әһәмияткә ия.

Бүгенге көндә алар тарафыннан уннан артык проект тормышка ашырыла. Алар арасында«Бөтендөнья татар яшьләре форумы» (2021 елда Россиянең 23 төбәгеннән 70 делегат, шулай ук Америка, Бөекбритания, Германия, Казахстан, Төркия яшьләр оешмалары җитәкчеләре катнашты);«Татарча диктант» Бөтендөнья акциясе (ул 34 чит ил һәм Россия Федерациясенең 71 төбәгеннән барлыгы 1 миллионнан артык (1 023 738) кешене берләштерде. Ә чараны үткәрү өчен бөтен дөнья буенча 4723, Татарстанда – 2029 мәйданчык оештырылган иде). Шулай ук, татар телендә «Ачык Университет»белем бирү платформасы оештырылды; «Акыл Фабрикасы» белем бирү – гамәли мәктәбе эшли; «Мин татарча сөйләшәм» акциясе һәм башкалар үкәрелде.

Татар яшьләре форумы үз эшен Казаннан читтә дә актив рәвештә алыпбара. Мәсәлән, Форум яңа татар мәдәнияте һәм урбанистика өлкәсендә яшьләр проектларын гамәлгә ашыручы URBANTATAR Яр Чаллы берләшмәсенә актив ярдәм күрсәтә. Берләшмә мәктәп укучылары һәм студентлар өчен ел саен «Татар

яшьләре форумы» воркшобы, «Кыскасы» кече прозаик формадагы әдәби лаборатория, заманча татар альтернативасы концертлары, яшь татар рәссамнары күргәзмәләре һ. б.сыйфатлы һәм заманча чаралар уздыра.

Шул ук вакытта URBANTATAR яшь командасы зур онлайн-проектлар белән дә шөгыльләнә,алар арасында – Яшьләр эшләре министрлыгы гранты чараларына тормышка ашырылган URBANTATAR халыкара интернет-радиосы һәм татар телендә UT PODCAST яшьләр подкасты.

**«Идел» яшьләр үзәге**башка төбәкләрдә яшәүче яшь татарлар-ватандашлар белән даими эш алып бара. Үзәк Россия Федерациясе территориясендә эшләүче 40тан артык татар яшьләре иҗтимагый оешмалары һәм берләшмәләре белән актив рәвештә хезмәттәшлек итә.

«Тарих эзләреннән» Бөтенрәсәй тарихи рәсемнәр конкурсы (аның максаты-Россия тарихы контекстында татар халкының тарихын белү дәрәҗәсен күтәрү); яшьләргә  социаль челтәрләрдә татар телендә үз блогын/сәхифәсен булдыру, алып бару һәм популярлаштыру өчен кирәкле күнекмәләр алуга юнәлдерелгән «ZAMAN» татар блогингы мәктәбе, «Иделем акчарлагы» яшь татар язучылары бәйгесе; татар балалар лидер мәктәбе һәм татар яшьләре лидеры мәктәбе; «Милләтебез хәзинәләре» проекты, һәм әлбәттә 30 ел рәттән үткәрелә торган, милли-мәдәни кыйммәтләргә, туган телгә якынайтуга юнәлтелгән Татар яшьләре көннәре проекты (узган елда яшьләр оешмасы лидерлары һәм активистлары арасында 180 кешене берләштерде).

Туган телебезне, мәдәниятебезне саклау һәм популярлаштыру безнең яшьләр оешмаларының көндәлек эшчәнлегендә дә чагыла. Без бергәләп «Милли-заманча» принцибы нигезендә төрледән-төрле чаралар уздырабыз. Мәсәлән, яшүсмерләр өчен уздырыла торган «Йолдызлык», эшләүче яшьләр өчен «Безнең заман» фестивалләрендә яңгыраган җырлар, укылган шигырьләр, татар халык биюләре. Шулай ук, яшь журналистларны ачыклауга, ике дәүләт телендә язучы профессиональ белгечләр әзерләүгә юнәлдерелгән«Алтын Каләм – Золотое перо» республика балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр матбугаты фестивален дә билгеләп үтәсем килә.

Безнең яшьләр үзәкләрендә һәм яшүсмерләр клубларында да милли тәрбия бирүгә юнәлдерелгән проектлар шактый.Мәсәлән, Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык»яшьләр үзәгендә «Шатлык яшьләре» татар яшьләре берләшмәсе эшләп килә. Берләшмә белән берлектә сәләтле яшьләргә ярдәм итү, Татарстан Республикасы халыкларының милли мәдәни традицияләрен яңарту һәм үстерүгә, гражданлык һәм милләтара бердәмлекне тәрбияләүгә юнәлтелгән «Татар егете» яшьләр проекты, «Халкым чишмәсе» иҗат фестивале, «Серле сандык» проекты кебек чаралар үткәрелә.

Аерым рәхмәт сүзләрен Марат Готыф улы сезгә җиткерәсем килә. Сезнең ярдәм белән иҗтимагый оешмалар белән уртак чаралар оештырылды. Мәсәлән: «Әйдә ШаяРТ» КВН Татар лигасының финал уены – татар телендә үткәрелә торган заманча телевизион юмористик уен һәм Сәләтнең мәгълүмати технологияләр өлкәсендә татар телен саклау һәм үстерү өчен кушымта һәм сервислар булдыруга юнәлдерелгән «IT-хакатоны».

Хәзерге вакытта «Милли – заманча» концепциясе үсешенең перспектив проектларының берсе – татар яшьләрен, проектларын берләштерүче мохит булдыру. Ул милләт, тел, гореф-гадәтләрне саклауга һәм заманчалаштыруга бәйле проектларны бергә җыючы, бу юнәлештә актив яшьләрне берләштерүче үзәк булачак.Бүгенге көндә Мәдәният министрлыгы һәм Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә «Парус» объектын яңарту эше алып барыла.

Фикеремне йомгаклап тагын бер кат шуны әйтәсем килә, яшьләрне җәлеп итә алырлык заманча продукт булдырганда гына аларда татар теленә, гореф-гадәтләребезгә карата кызыксыну уята алабыз. Гомумән, татар яшьләре генә түгел, ә төрле милләт яшьләре дә милли һәм заманча проектларга тартыла. Яшьләр белән яшьләр өчен эшләвебезне дәвам итәбез.